«Ак калфак» форумы: без уйландык, без уяндык...

«Ак калфак» хатын-кызлар форумына 41 төбәктән, 18 чит илдән барлыгы 500дән артык делегат җыелды. Бернечә ел элек кенә: «Калфак юк, милли киемнәр юк», – дип йөргән хатын-кызларыбыз быел бик тә затлы, купшы итеп киенеп килгәннәр, һәркемнең башында калфак. Җыенга калфак белән килү – төп шарт.

4 БИТ

«Кичер, улым!»

«Бу хатны мин улыма яздым. Ләкин ул хатлар барып җитә торган җирдә түгел инде хәзер. Исәннәр укысыннар да гыйбрәт алсыннар», – диде ятим ана, яшьле күзләрен сөртеп. Һәрбер юлда – җан авазы, үкенеч, сагыш...

7 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 18.04.2017 | №41 (5803)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ТАРИХИ УТЫРЫШ: РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ ПРЕМЬЕР КӘНӘФИЕНӘ ХУҖА ТАПТЫ

Дәүләт Советының кичәге утырышында бернечә тарихи вакыйга булды. Депутатлар Татарстанның яңа премьер-министрын расладылар һәм моңарчы бистә булган Кукмараны шәһәр иттеләр.

gossov.tatarstan.ru

Линар ЗАКИРОВ

ШӘЙМИЕВ НИ ДИДЕ?

Илдар Халиков үз теләге белән республиканың хөкүмәт рәисе кәнәфиен калдыргач, «Яңа премьер кем булыр?» дигән сәяси интрига ике атна дәвам итте. Дәүләт Советына Алексей Песошин кандидатурасын республика Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдим итте.

Исегезгә төшерәбез, Песошин 2014 елда республика премьер-министры урынбасары булып эшли башлады, торак-коммуналь хуҗалык, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәләре өчен җаваплы иде. Хәзер аның җаваплылык кыры бермә-бер киңәячәк.

– Бүгенге хөкүмәт – нәтиҗәле эшләүче административ команда. Дәүләт хакимиятенең барлык структуралары үзара аңлашып эшли, федераль органнар белән дә тыгыз бәйләнештә без. Республиканың сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләре, әйдәп баручы финанс һәм бизнес вәкилләре белән бәйләнешларыбыз көчле. 2030 елга кадәр исәпләнгән стратегияне хәл итүдә дә җитди бурычлар тора. Алексей Песошин зур хезмәт юлы үтте: бизнес структураларында эшләде, Казанның Башкарма комитет рәисе булды, – дип сөйләде Рөстәм Миңнеханов.

Премьер-министр булып расланганчы, Песошин парламент трибунасы янына чыгып, тормышның кайсы өлкәләренә игътибарны юнәлтергә кирәклеге турында сөйләде.

– Татарстан Президенты билгеләгән бурычларны хәл итүдә хөкүмәт, депутатлар корпусы һәм муниципаль берәмлекләр белән бер команда булып эшләү өчен бөтен көчемне куярга әзермен, дип ышандыра алам, – диде ул.

Әйткән сүз – аткан ук дигәндәй, Алексей Песошинның сүзе белән гамәле тәңгәл килер, дип без дә ышанып калабыз.

Шушындый тарихи вакыйга барышында Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә сүз алды.

– Дәүләт хакимияте органнарының эш функцияләре мәсьәләсендә безгә хөкүмәт вәкилләренең абруен күтәрергә кирәк. Бу бик мөһим, чөнки эшлисе эшләр чиксез күп, һәркем «үз чемоданын күтәреп барырга» тиеш, – дип, үз тәкъдимен җиткерде ул.

Сессияне Кукмара халкы аеруча зур кызыксыну белән күзәтеп утырганнар. Чөнки нәкъ менә кичә алар 17,5 мең кешелек бистә халкыннан шәһәр кешеләренә әйләнде. Хәтерләсәгез, үткән елның 20 ноябрендә узган референдумда Кукмара халкының 67 проценты катнашып, тавыш бирүчеләрнең 80 проценты уңай тавыш бирде. Депутатлар фикеренчә, Кукмараның шәһәр статусын алуы андагы сәнәгать паркларына инвесторларны җәлеп итү мөмкинлеген бирәчәк.

ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДА ТАТАРСТАННЫҢ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЛАРЫ

Мөхәммәт Сабиров – 1990 елның 30 августыннан 1995 елның 16 гыйнварына кадәр.

Фәрит Мөхәммәтшин – 1995 елның 16 гыйнварыннан 1998 елның 28 маена кадәр.

Рөстәм Миңнеханов – 1998 елның 10 июленнән 2010 елның 25 мартына кадәр.

Илдар Халиков – 2010 елның 22 апреленнән 2017 елның 3 апреленә кадәр.

→ Ахыры 3нче биттә.

Татарстан мөфтие:

«Имамнарның җәмгыятьтәге абруен күтәрәсе бар»

Татарстан мөселманнарының VII корылтаенда Татарстан мөфтие булып янә Камил хәзрәт Сәмигуллин сайланды. Баш казый вазифасын элеккеге Татарстан казые Җәлил хәзрәт Фазлыев башкарачак. Ә мөфтинең беренче урынбасары итеп Казанның «Котдус» мәчете имам хатибы Рөстәм хәзрәт Вәлиуллинны сайладылар.

president.tatarstan.ru

Съездда бөтен республика буенча 950дән артык делегат катнашты, алар арасында шәһәр-районнардан килгән имамнар, республика министрлыклары вәкилләре, район башлыклары да бар иде. Корылтай эшендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Ул үзенең чыгышында соңгы дүрт елда республикада күп үзгәрешләр булуын, аеруча милләтара һәм конфессияара дуслыкның ныгуын билгеләп үтте. Аның сүзләренчә, бу эштә Татарстан Мөселманнары диния нәзарәтенең дә өлеше зур булды.

– Бүген республикада динне, гореф-гадәтләрне һәм телне саклап калу өчен барлык шартлар тудырылган. Тиздән үз ишекләрен ачачак Болгар ислам академиясе дини мәгариф үзәге булыр, анда зыялы дин белгечләре әзерләнер дип өметләнәбез, – дип белдерде ул.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да чыгышының башында Татарстанда төрле милләтләрнең дус яшәвен, төрле конфессия вәкилләренең үзара ихтирамлы мөнәсәбәттә булуларын искә алды.

– Болар барысы да республикабызның имин үсешен тәэмин итә. Татарстанда, диннәр төрле булуга карамастан, әхлакый кыйммәтләр һәм кыйблалар бөтен милләтләр өчен дә гомум. Шул ук вакытта экстремизм һәм терроризм идеологиясенә каршы тору мәсьәләләренә дә кагылмыйча булдыра алмыйм. Татарстан – күпсанлы мөселманнар яшәгән, икътисади яктан алга киткән республика. Икътисади үсешкә ирешкән субъектлар һәрвакыт радикаль көчләр өчен мишень булып тора. Чөнки мондый төбәкләр, беренчедән, матди база буларак кабул ителә; икенчедән, күпсанлы мигрантлар арасында билгеле бер җимергеч сәясәт алып бару өчен уңайлы җирлек булып тора. Шуңа күрә безнең өчен әлеге тенденцияләргә каршы торырга һәм чит йогынтыга бирелми кала белү бик мөһим. Диннәр арасындагы яхшы һәм күркәм мөнәсәбәтләрне саклап калу киләчәктәге үсешнең һәм яшәешнең төп шарты булып тора, – диде ул.

Татарстан илнең башка субъектларыннан тагын бер уңай ягы белән аерылып тора – республика өммәте бердәм, ә мөфтият – бердәнбер. Мәхәлләләр саны буенча безнең нәзарәт Россия мөфтиятләре арасында беренче урында тора.

Мөфти нәзарәт эшчәнлеге белән дә таныштырды, алдагы көннәргә бурычлар куйды.

– Безнең бурыч: дини оешмаларны берләштерү, аларның эшчәнлеген Коръән һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәднең сөннәтенә, имам Әбү Ханифә юнәлешенә нигезләү һәм бердәй кануни үрнәккә китерү, татар дин галимнәренең хезмәтләрен өйрәнүне дәвам итү, татар дини-фәнни мәктәбен торгызу, милли үзаңны һәм телне саклау. Әлегә кадәр мөгаллимнәр арасында ислам һәм шәригать фәннәре буенча магистр яки фән докторы дәрәҗәсендәге белгечләр юк иде. Болгар ислам академиясен ачу бу мәсьәләне хәл итәр дип өметләнәбез. Имамнарның җәмгыятьтәге абруен күтәрәсе бар. Имамнарга һәм аларның ихтыяҗларына йөз белән борылырга, хокукларын якларга кирәк. Көнүзәк мәсьәлә булып гомумроссия ислам телевизион каналын булдыру тора. Әлеге медиапроект рухи-әхлакый кыйммәтләрне, Россиядә яшәүче мөселман халыкларының милли мәдәниятен популярлаштырырга ярдәм итә алыр иде, – дип сөйләде ул.

Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев казыйларны аеруча борчыган мәсьәләләргә тукталды.

– Казыйларны иң борчыган мәсьәләләрнең берсе – аерылышучыларның саны арту. Мөселманнар арасында да шактый ул талак проблемасы. Шуңа да без, районнарда гаиләне саклау үзәкләре оештырырга кирәк, дигән фикердә торабыз. Әйтик, Балтач районында әлеге эшне без ЗАГС белән берлектә алып барабыз. Икенче борчыган мәсьәлә – эшмәкәрләрнең үзара бер фикергә килә алмавы. Уртак эшне башлаганда килешү төземиләр, милек һәм керемне бүлешә башлагач, алар арасында низаг туа. Әлеге уңайдан мирас мәсьәләләре буенча судьялар белән махсус совет булдыру идеясе бар, – дип сөйләде ул.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

САН

*1989 елда Россиядә **174** мәхәллә булган. **1995** елда Татарстан буенча гына да аларның саны **700**гә тулган. Бүгенге көндә республикабызда **1415** мәхәллә һәм **1430** мәчет исәпләнә. Анда **1400**гә якын имам хезмәт куя. Диния нәзарәтенең территориаль башкарма органнарын **48** мөхтәсибәт һәм **9** казыят тәшкил итә. Соңгы дүрт елда Татарстанда **50**дән артык яңа мәчет ачылган. Агымдагы елның **15** сентябрендә Татарстанда диния нәзарәте барлыкка килүгә **25** ел тула.*

Виталий Мутко:

«Казан әзерлек ягыннан беркайчан да шик тудырмады»

Узган атнада, җомга көнне, Россия хөкүмәте рәисе урынбасары Виталий Мутко эш сәфәре белән Казанга килде. Ул «Казан-Арена» стадионының Конфедерация кубогына әзерлеге белән танышты, тест матчларына багышланган җыелыш үткәрде.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

– Казан әзерлек ягыннан беркайчан да шик тудырмады. Без монда бүген зур делегация: оештыру комитеты, федераль хезмәткәрләр, сак өчен җаваплы кешеләр белән килдек. Казанның ни дәрәҗәдә әзер икәнен бергәләп тикшерәбез. Бүген инде стадионга керү системасын, кунакханәләр әзерлеген, күнегү мәйданчыкларын карап чыгарга өлгердек. Стадион буенча шуны әйтә алам – ул бездә бернинди шик-шөбһә тудырмый. ФИФА белгечләре стадиондагы газон белән канәгать булу белешмәсен тапшырды. Матбугат зонасын зурайту, VIP зонаны рәтләү, вакытлы трибуналарны төзекләндерү кебек вак-төяк эшләр генә калды. Башка сораулар юк, барысы да график буенча бара. «Рубин»ның «Казан-Арена»да булачак уены безнең өчен Конфедерация кубогы алдыннан сынау матчлары булыр. Шул вакытта ФИФА коллегалары белән стадионга керү системасын җайга салырбыз. Казан безне һәрвакыттагыча сынатмас, дип өметләнәм. Россия җыелмасы да бирелә Мексика командасы белән уңышлы чыгыш ясар, – диде Виталий Мутко.

Хөкүмәт рәисе, Конфедерация кубогына әзерлекнең бары тик бер кимчелеге бар, ди. Ярышларга нибары ике ай вакыт калуга карамастан, әлегә билетларның өчтән бере генә (200 мең билет) сатылган. Тагын 700 мең билетны сатарга кирәк.

– 19 апрельдән билет сату үзәкләре ачылачак, бәлки шул вакытта футбол җанатарлары активлашыр, – ди Виталий Мутко.

Конфедерация кубогын Казаннан тыш, Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Сочи шәһәрләре кабул итәчәк. Хөкүмәт рәисе урынбасары сүзләренчә, бу шәһәрләр юкка гына сайланмаган.

– Иң беренче чиратта инфраструктура, юллар төзеклеге, шәһәрнең зур чараларны кабул итү мөмкинлегенә карадык. Казан – Универсиада, Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионатын кабул иткән шәһәр. Әле кичә генә 2023 елга кадәр спорт чаралары календаре белән таныштым. Кайсы гына елны ачсаң да, Казанны күрәсең. Бу – шәһәрнең үз теләге генә түгел, ә халыкара спорт оешмалары үзләре Казанны сайлый дигән сүз. Шуңа да стадионнарны сайлаганда, Казанның урыны бәхәссез иде. Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочида да чемпионатны кабул итәр өчен бөтен мөмкинлек бар, – диде Виталий Мутко.

Алисә САБИРОВА.

Тарихи утырыш: Рөстәм Миңнеханов премьер кәнәфиенә хуҗа тапты

→ Ахыры. Башы 1нче биттә.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

РЕСПУБЛИКАДА ТЕЛЕФОН ЭЛЕМТӘСЕ НИК НАЧАРЛАНА?

Билгеле булганча, Дәүсоветтагылар Татарстанның азык-төлек куркынычсызлыгы турында закон проектын әзерли. Ул беренче укылышта кабул ителеп, икенче укылышка да әзер булып кирәргә тиеш иде. Әмма парламентның экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе Таһир Һадиев депутатлардан икенче укылышка төзәтмә кертү вакытын 17 майга кадәр озайтырга рөхсәт бирүләрен сорады. Парламентарийлар рөхсәт бирде.

Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, бу бик әһәмиятле документ, аны күп төрле иләкләр аша үткәрергә кирәк.

– Җирле товар җитештерүчеләргә ярдәм күрсәтү, авылда яшәүче халыкның эш активлыгын арттыру белән бергәттән, шушы документ ярдәмендә аларга авыл хуҗалыгы продукциясен җыю һәм сату мөмкинлеген дә булдырырга кирәк, – диде ул.

Татарстан Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Тимур Нагуманов, депутатлар алдына чыгып, 2016 елда ниләр эшләгәннәрен сөйләде. Былтыр республика Президенты каршындагы эшкуарлык советы эшли башлады. Биредә эшкуарлар һәм дәүләт органнары, уртак тел табып, катлаулы мәсьәләләрне җиңел генә чишү юлларын эзлиләр.

– Тәҗрибә күрсәткәнчә, мондый форматның әһәмияте зур. Безнең белән республиканың 20 меңгә якын эшкуары элемтәдә тора, – диде Тимур Нагуманов.

Хөкүмәт сәгатендә депутатлар алдында электрон хезмәт күрсәтү буенча мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов чыгыш ясады. Аның әйтүенчә, ике ел элек эшли башлаган «Халык инспекторы» системасы популярлык казана бара. Хәтерләсәгез, телефонга йөкләнә торган әлеге программа юллардагы тәртип бозуларны киметү максаты белән эшләнгән иде. 2017 елның беренче өч аенда 10 мең гариза килеп ирешкән, барлыгы 9 миллион сум күләмендә штрафлар түләнгән.

Депутатлар Роман Шәйхетдиновны сорау бирмичә җибәрмәде. Альберт Хәбибуллин әйтүенчә, республиканың кайбер җирләрендә телефон элемтәсе бик начар тота. Бу бигрәк тә Чаллы, Әгерҗе якларына барганда сизелә, диде ул. Депутат әлеге мәсьәләнең кайчанрак хәл ителүе белән кызыксынды. Министр мондый проблема барлыгын таныды.

– Соңгы арада шундый хәл күзәтелә: элемтә операторлары үзләренең радиоантенналарын әз кеше яши торган урыннан шәһәр җиренә, ягъни күп кешелек территорияләргә күчерә. Шуның аркасында шәһәрләр арасындагы маршрутларда элемтә бик начарланды. Узган елның ноябрендә махсус транспорт белән республикадагы бөтен юлларны йөреп чыгып, элемтә сыйфатын тикшердек. Нәтиҗәләр белән Россия элемтә һәм гаммәви коммуникация сайтында танышырга була, – диде Роман Шәйхетдинов.

Аның әйтүенчә, телефон элемтәсе начар булган очракта, шикаятьләрне «Халык контроле» порталына юлларга кирәк.

Нәрсәләр алар: вейкборд, фудтрак, вендинг?

Казан мэры Илсур Метшин кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә башкалада санитар чистарту чараларын дәвам итәргә, туристлык чорына ныклы әзерләнергә кирәклеген ассызыклады.

kukuruzkin.ru

– Казанлылар да, кунаклар да канәгать калырлык булсын, – диде шәһәр башлыгы.

Мәгълүм ки, Казанда быелның 17 июненнән 2 июльгә кадәр Конфедерация кубогына футбол матчлары узачак. Җәйге урам сәүдәсен оештыруга шушы спорт чарасы билгеле бер йогынты ясаган. «Казан-Арена» футбол стадионы территориясендә ачык һавада сәүдә киосклары урнаштырылмаячак. Борчылырга кирәкми, шәһәр урамнарында, паркларда һәм скверларда ачык һавада сәүдә үткәрү өчен 500гә якын урын билгеләнгән.

– Аукционнар аша 305 урын инде рәсмиләштерелде. Аларда милли ризыклар сатылачак, сувенирлар, фотохезмәтләр тәкъдим ителәчәк, аттракционнар, скутер, велосипед прокатлары эшләячәк, – дип әйтеп үтте үзенең чыгышында шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Иван Кузнецов.

Безне әле тагын колак ишетмәгән вейкборд, фудтрак, вендинг кебек яңалыклар көтә. Вейкборд – спортның су чаңгысын, су тактасын, трамплиннан сикерүне, акробатиканы, тау чаңгысын берләштергән төре. Кабан күлендә һәм Казансу елгасында моңа тәвәккәллек иткән кешеләрне Ходай имин-лектән аермасын! Фудтрак – ашамлыклар яки башка төрле продукция сатыла торган кечкенә арба-фургон. Урамнарда һәм паркларда бизәкле «чегән арбасы» күрсәгез, шикләнеп калмассыз. Газлы су сатучы автомат-җиһазларны һәммәбез хәтерли. Үзебезне Европа дәрәҗәсендә хис итеп, хәзер инде без дә аларны «вендинг», дип сөйләшәчәкбез. Инглиз телендә vend – сату итү. Чәйне һәм кофены урамнардагы вендинг сәүдә рәтләрендәге автомат-җиһазлардан гына алып эчәрбез.

Эшкуарлар арасында әлегә паркларда «җәйге кинотеатр» оештырырга, һава шарларында очырырга теләүчеләр табылмаган.

– Җәйге чорда урам сәүдәсе өчен урын сатып алынып, киоск куелган җиргә җыен «казаклар-разбойниклар» сыенмасын. Рөхсәтсез рәвештә теләсә кая куела торган киоскларны полициянең терәк пунктлары да, шулай ук халык «милиционерлары» да күзәтчелектә тотсын иде, – дип фикерен әйтте мэр Илсур Метшин.

Казанда рөхсәтсез рәвештә урнаштырылган киоскларны ачыклау максатында, махсус айлык башланды. Рөхсәтсез сәүдә оештыручыларның сәүдә җиһазлары мәҗбүри тартып алыначак», – дип кисәтте Иван Кузнецов.

Дамир БӘДРИЕВ.

КИСӘТҮ

Татарстанда һава торышы үзгәрә

19-21 апрель көннәрендә Татарстанда һава һәм юл торышы шартлары үзгәрәчәк.

Республикада юеш кар һәм яңгыр явуы, урыны белән көчле җил исүе көтелә, дип кисәтә синоптиклар. 20 һәм 21 апрельдә җилнең тизлеге секундына 17-22 метрга җитәчәк.

Бу көннәрдә һава температурасы 3 градус салкыннан 2 градуска кадәр җылы булачак дип фаразлыйлар. 19-20 апрельдә республиканың көньяк һәм көнчыгыш районнарында 8-10 градуска кадәр җылытачак. Әлеге кискен үзгәрешләр республика территориясенә көньяк циклон килү белән бәйле. Юлларда кар өемнәре һәм бозлавык булырга мөмкин. Сак һәм игътибарлы булыгыз!

«Ак калфак» форумы: без уйландык, без уяндык...

realnoevremya.ru

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Казанда бишенче тапкыр «Ак калфак» хатын-кызлар форумы узды. 41 төбәктән, 18 чит илдән барлыгы 500дән артык делегат җыелды. Берничә ел элек кенә: «Калфак юк, милли киемнәр юк», – дип йөргән хатын-кызларыбыз быел бик тә затлы, купшы итеп киенеп килгәннәр, һәркемнең башында калфак. Җыенга калфак белән килү – төп шарт.

–Чыгышымда бераз усалрак та булырга туры килер, бәлки кемнәргәдер бу ошап та бетмәс, – дип кисәтеп куйды үзенең чыгышының башында ук «Ак калфак» иҗтимагый оешмасының җитәкчесе Кадрия Идрисова.

Аның сүзләреннән аңлашылганча, әгәр дә биредә алынган тәҗрибә урыннарда кулланылмаса, сөйләгән сүзләрнең, күп төрле семинарларның бернинди файдасы да юк. Моның өчен «Ак калфак» оешмасының төбәктәге җитәкчеләренең үз артларыннан халыкны ияртә ала торган көчле шәхесләр булулары кирәк. Бары тик шул очракта гына тотылган чыгымнар, куйган тырышлык үз-үзен аклаячак.

Май башында Казанга пешекчеләр җыйналса, ай ахырында Салават шәһәрендә Шәҗәрә бәйрәме булачак. Аннан соң Сабада васыятьнамә язу буенча тәҗрибә уртаклашу көтелә. «Орчык бәйрәме», «Бәби туе»... Эш алымнарының ниндиләре генә юк. Кадрия Идрисова әйткәнне хуплап, бу тиклем тырышлыкларның файдасы гына булсын инде, диясе килә.

Татарлар нинди генә форумга, җыенга җыйналмасыннар, төп сорау булып тел мәсьәләсе кала.

– Соңгы 20-25 елда туган телне сакларга кирәк дип күп сөйлибез. Туган телне кем сакларга тиеш: дәүләтме, гаиләме дибез. Миңа калса, без һаман бер урында торабыз кебек. Туган тел тәрбиясе, әлбәттә, гаиләдә бирелә. Монда җыелган хатын-кызларны бала тәрбияләргә өйрәтергә алынмыйм, бары тик үзебезнең гаиләнең тәҗрибәсе белән генә уртаклашасым килә. Без гаиләдә өч малай, Казанда бердәнбер татар мәктәбе булган, урамнарда бер авыз татарча сөйләшмәгән елларда үстек, белем алдык. Укырга кергәндә, мин русча бер сүз дә белми идем. Бу миңа рус мәктәбендә төпле белем алырга комачаулык итмәде, бернинди акцент та юк. Үзебезнең кызларыбыз да балалар бакчасына барганчы бары тик татарча гына сөйләшәләр иде, рус теленә шунда өйрәнделәр, аннан соң да өйдә һәрвакыт татарча гына аралаштык. Ике оныгыбыз бар, әлегә балалар бакчасына йөрмиләр, татарча гына сөйләшәләр. Киләчәктә дә шулай булачак. Театрларга, әдәби кичәләргә йөрү, туганнар белән аралашу – болар барысы да туган телне саклауга үз өлешен кертә, – диде үзенең чыгышында Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗев.

Урыным Савченко Сәйдә ханым белән янәшә туры килде. Ул үзе генә түгел, әнисе дә чит төбәктә туып-үскән. Телне дә камил белә, диненнән дә ваз кичмәгән.

– Әниләрем, әбиләрем кайларда гына яшәмәгәннәр. Үзем дә Сәмәркандта туып-үстем. Мәскәүдә укып, шунда тормышка чыктым. Томск шәһәрендә 25 ел яшәдек, өч бала үстердек. Аннан соң 25 ел Нальчик шәһәрендә тордык. Татар конгрессы оештырган чараларда ун ел катнашам, ел да Казанга киләм. Туган җиргә, тарихи Ватаныбызга кайту теләген сүзләр белән генә аңлатырлык түгел. Ике тапкыр Мәккәдә булдым. Кемнәрдер анда барганда юлда үлеп калуны изге үлемнәрдән саный. Һәрчак уйлый торган идем: минем өчен иң изге туфрак Татарстанда, каберләрем шунда булса иде. Аллага шөкер, быел менә күченеп кайттык. «Без түгел, безне ашаган кошлар да туган җирне күрә алмас инде», – дип җырлыйлар иде әбиләрем. Бүгенге көндә Татарстан үзенең ул-кызларын барлый, җыйный. Читтә яшәүчеләр өчен бу бик тә кадерле, – ди Сәйдә ханым.

Рус телендә бердәнбер чыгыш ясаучы Түмән өлкәсеннән Әлфия Кәбирова булды. Шулай да аның чыгышы нечкәтер күңелгә кереп калды. Алар, «Әбием» сүзен үзләренең брендлары итеп алып, бернинчә төрле товар җитештерәләр.

– Бервакыт миңа өлкән яшьтәге апалар белән бер чарада катнашырга туры килде. Алар миңа үземнең дәү әниемне искә төшерделәр. «Авылда яшьләр юк, күбебез ялгыз. Нәрсә өчен яшәгәнне дә белгән юк. Кайчакта, кичтән ятып, иртән уянасы килмәгән вакытлар да була», – дип сөйләделәр. Бу минем күңелемне бик нык кузгатты. Аларның тормышларын бизисем килде, иртән шатлык белән уянуларын теләдем. Шулай итеп без, түгәрәкләргә җыйналып, кул эшләре белән шөгыльләнә башладык, соңрак товар җитештерүгә күчтек, – дип сөйли үз тәҗрибәсе турында Әлфия Кәбирова.

Оренбург өлкәсендә исә кече яшьтән мәктәп балаларын шәл бәйләргә өйрәтәләр. Атнасына өч тапкыр махсус дәресләр оештырыла. Оренбург шәлчеләр предприятиесе моның өчен акча түли. Шулай итеп алар авылларны саклап калмакчылар. Әлбәттә инде, данлыклы Оренбург шәлчеләренең һөнәрләрен дә югалтырга теләмиләр.

Мәскәүдән килгән билгеле җырчыбыз Наилә Фатехова үзенең фикерен җыр аша аңлатты. «Без үлмәдек, без уйландык, без уяндык», – дигән сүзләр бар иде җырда. Бирсен Ходай.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА.

Соңгы араларда нишләптер борчулы хәбәрләр ешрак ишетелә дигән уйларымны таратып, Ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруда алмаш гаиләләр әзерләүдә ярдәм итүче республика үзәге директоры Светлана Богова шатлыклы хәбәр җиткерде. «Шушы көннәрдә генә тәрбиягә бала алган Казанда яшәүче өч гаилә тиздән үзләре торачак яңа фатирларын карап кайткан».

Сөенче!

Аларга бу яңа нигезне шәһәребез мэры Илсур Метшин һәм шәһәр хакимияте «Шәфкатьле Казан» программасын үтәү максатыннан бирергә булган. Шәһәр хакимиятенең һәм мэрның әлеге игелекле адымы башкалабызның ятимнәр проблемасын тизрәк чишәргә булышыр. Чөнки әлеге өч гаилә тагын 12 баланы үзләренең җылы кочакларына алырга тәвәккәлләгәннәр. Әлеге балалар сәламәтлеккә туймаган – мөмкинлекләре чикләнгән һәм үсмерләр. Белгәнебезчә, мондый сабыйларны беркем дә үз гаиләсенә алырга атлыгып тормый. Шуңа алар күп очракта балалар йортларында үсәргә мәҗбүр.

Әлеге өч гаиләне мин үзем дә яхшы беләм, бу хакта ишеткәч, шатланып туя алмадым. Маша белән Денис Широковлар икесе дә педагоглар. Аларның тәрбиягә алган уллары Семенның язмышын Ходай дошманыңа да күрсәтмәсен. Әнисе ул бала чакта ук үлгән. Ана назыннан мәхрүм калган малай кызыкны урамнан эзли башлый. Хөкем карары, аннары – тәртибендә тайпылышлар булган балалар һәм үсмерләр өчен махсус гомуми белем бирү республика мәктәбе... Өч елдан соң вакыты җитеп, өенә кайтам дип шатланып кына торганда, башта әтисе үлеп китә, аннары апасы юл фаҗигасендә һәлак була. Җиде юл чатында япа-ялгыз калган үсмерне нәкъ менә шул чакта үзләренә сыендырды да инде әлеге гаилә. Аңарчы да аларда бер егет тәрбияләнгән иде. Анысының да язмыш юлы шактый сикәлтәле. Хәзер егет үскән инде, ләкин һаман шул җылы ояда. Калган ике гаилә дә шундый ук игелекле, олы йөрәкле. Алар да ятим үсмерләр, авыру сабыйларның бетмәс мәшәкатьләреннән курыкып тормаганнар, үзләренә тәрбиягә алганнар.

Яңа фатирлар өлкәннәргә дә, балаларга да бик ошаган. Дөрес, Киров районындагы «Идел култыгы» дип аталган бистәдәге бу яңа йорттагы зур фатирларга әле обойлар да ябыштырылмаган, линолеум да җәелмәгән. Аларын бәхетле хуҗалар бергәләп киңәшеп үзләре сайлап алачак. Үзләренә шунда яшисе бит.

– Бу фатирларны җиһазлау һәм көнкүреш приборлары алу өчен иганәчеләр эзләп табасы бар әле, ләкин фатирлы булу янында моныс бик кечкенә мәсьәлә. Иң мөһиме: баш өстендә – түбә, – диде Светлана Богова, шатлыгын яшермичә.

Барлык эшләрне дә 1 июнь – Балаларны яклау көненә тәмамларга һәм әлеге гаиләләргә тантаналы төстә ачкычлар тапшырырга уйлап тора Казан хакимияте.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

ТРАНСПОРТ

Әйдәгез, бакчаларга!

Шәһәр Башкарма комитетының транспорт комитеты рәисе Айдар Абдулхаков 29 апрельдән Казанда җиде бакчачылык ширкәтенә автобус маршрутлары ачылачагын хәбәр итте. Бакчачылык ширкәтләренә пассажирлар йөртү тарифлары узган елгы чикләрдә калдырылган.

Маршрутлар:

39нчы «Ветеринар институт – Дәрвишләр станциясе бистәсе»

41нче «39нчы квартал – «Щербаковка» бакчачылык ширкәте»

92нче «Ленин исемендәге мәдәният–ял комплексы – Дальные сады»

101 нче «Горький шоссесы – «Текстильщик» бакчачылык ширкәте»

106нчы «Җиңү проспекты – Арышхазда»

109нчы «Совет мәйданы – Яңа Шигали»

111нче «Җиңү проспекты – «Жиркомбинат» бакчачылык ширкәте»

Автобуслар 6.00-21.00 сәгатьләрдә йөри.

ФОТОСУРӘТЛӘРДӘ – ТАРИХ

Узган атнада Татарстан Республикасы Ветераннар советы Бөек Ватан сугышы чорында төшерелгән 2 меңгә якын фотоны Татарстанның Милли музеена тапшырды. Килешүгә кул кую чарасы тантаналы рәвештә Казан Кремленең Бөек Ватан сугышы тарихы музей-мемориалында узды. Әлеге фотолар ике ел дәвамында «Бөек Ватан сугышының гаилә фотохроникалары» проекты кысаларына җыелган.

Ветераннар советы рәисе Хәбир Иштирәков әлеге документларны музей директоры кулына шәхсән үзе тапшырды.

– Җиңү бәйрәменә санаулы көннәр калды. Россиядә яшәүче һәр кеше өчен бу – изге көн. Әтиәниләр, әби-бабайларыбыз кичергән коточкыч куркыныч афәтне без елдан-ел ачырак тоябыз. Бурычыбыз – аларның хәтерен саклап калу, киләчәк буынга тапшыру. Минем әти бөтен сугышны узган кеше. Бер фотосы бар иде, ләкин бүген без аны таба алмыйбыз. Менә шундый әйберне булдырмас өчен, бу проект кирәк иде, – диде ул.

Проектны оештыруда мәктәп укучылары, район җитәкчеләре, ветераннар үзләре дә актив катнашкан. Ә фотолар җыю кебек җаваплы эшне Казанның Совет районы Ветераннар советы белән Дәүләт Советы депутаты Марат Шәгитов үз өстенә алган. Милли музейдан тыш, бу фотолар шулай ук Россия дәүләт кинофотодокументлар архивында да сакланачак әле.

– «Гаилә фотохроникалары» тик торганнан гына барлыкка килгән әйбер түгел ул. Россиянең, Татарстанның сугыш афәте кагылмаган бер генә гаиләсе дә юк. Һәр гаиләнең үз батыры, үз тарихы бар. Сугыш елларында гаилә ил тоткасы булган. Безнең акция үткәнне генә түгел, киләчәкне дә тоташтыра, – диде Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева.

ВЕТЕРАННАРГА БУШЛАЙ ЮРИДИК ЯРДӘМ

Татарстанның Юстиция министрлыгы 27 апрельдә Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм аларның гаиләләренә бушлай юридик ярдәм күрсәтү оештыра. Чарада Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге, Федераль салым хезмәтенең Татарстан идарәсе, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе, Татарстанның медик-социаль экспертиза баш бюросы, төрле министрлыклар, Дәүләт торак инспекциясе, Казан Башкарма комитетының Җир һәм милек мәсьәләләре, шулай ук Торак сәясәте комитеты вәкилләре, адвокат, нотариуслар катнашачак.

Казанлылар бушлай юридик ярдәм алу өчен 27 апрельдә сәгать 10.00-13.00гә кадәр Халыклар дуслыгы йортына (Казан, Павлюхин ур., 57нче йорт, 1к) мөрәҗәгать итә ала. «Павлюхин урамы» тукталышына кадәр 4,5,25,43,68,71,77нче автобуслар бара. Әлеге чара турында тулырак мәгълүматны **(843) 223-02-13** телефоны аша белешергә була.

Сак булыгыз: «йолдызлыкотрянка»

Татарстанда инде февраль башыннан бирле 70 меңгә якын бала үзенчәлекле авыру – «йолдызлыкотрянка» белән чирли. Авыруны бары тик сәләтле балалар гына йоктыра икән. Сабыйлар сәхнәгә бер чыкса, бертуктамый җырлый, бии башлыйлар. Әнә шундый балалар 14 апрель көнне УНИКС концертлар залында зур бәйрәм оештырды. Аларны икенче төрле «Йолдызлык» балалары дип тә әйтәләр әле.

«Созвездие-Йолдызлык» республика ачык телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале быел инде XVII тапкыр оештырыла. Аны Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, сәләтле балаларны барлау, иҗат мөмкинлекләрен үстерү максатыннан, үз карамагына алды.

– «Йолдызлык» – самимилек, сәләт, матурлык, ихласлык мохите. Бүген балалар сәләтен күрсәтү өчен, безнең республикада барысы да бар. Бу сәхнәдә без бүген мөгаллимнәр, әти-әниләр, район җитәкчеләре, балалар хезмәтен күрәбез. Матурлык һәм хезмәт бәйрәме бүген, – диде Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерү фонды башкарма директоры Нурия Хашимова.

Россия театр сәнгате университетының (ГИТИС) эстрада бүлеге кафедра мөдире Михаил Борисов та ел саен биредә үз уку йортына кабул итү өчен сәләтләр барлый. «Йолдызлык» фестиваленең Гран-приена ия булган балага әлеге уку йортында бушлай белем алу хокукы бирелә. Михаил Борисов үз чыгышында ерак революция чорларын искә алды.

– УНИКСтан 200 метр аралыкта гына Владимир Ленинга һәйкәл тора. Моннан бик күп еллар элек аны, революцион эшчәнлеге өчен, Казан университетыннан куганнар. Ә беләсезме нигә? Ул вакытта «Йолдызлык» хәрәкәте юк иде. Ул булса, Ленин берәр хор коллективында җырлар иде, бәлки Крупская белән биеп тә йөрер иде. Ярый әле хәзер «Йолдызлык» бар, балалар үзләренең сәләтләрен иҗат өлкәсендә күрсәтә ала, – дип ярым шаярып, ярым җитди сүз белән җөпләде фикерен Михаил Борисов.

Татарстан Республикасының һөнәри сәнгать һәм сәнгать белеме бүлеге мөдире Диләрә Хәйретдинова «Йолдызлык»ны һөнәри үсешкә трамплин дип саный.

– «Йолдызлык» безнең иң кадерле кыйммәтләрне – сәләтле балаларны барлаган Татарстан бренды. Сабыйларның елмаюын, күзләрендәге нурны күрү – үзе зур шатлык. «Йолдызлык» һәр катнашучы өчен иҗат дөньясына трамплин булып тора. Бу бәйгедән соң күбесе зур сәхнәгә чыга, – ди Диләрә Хәйретдинова.

yalkyn.com

Ә менә 19 яшьлек Гөлназ Гатина, ГИТИСка укырга керергә тәкъдим итсәләр дә, сәхнә юлыннан читтән баш тарткан. «Йолдызлык»та ул инде унынчы елын чыгыш ясый. Елмаеп кына, «Бу минем юбилей елым», – ди. Гөлназ Чирмешән районының Кармыш авылында туып-үскән. Хәзерге вакытта КФУда икътисадчы һөнәрен үзләштерә.

– «Йолдызлык»та вокал – иң авыр номинацияләрнең берсе. Бирегә Мәскәүдә белем алган иң көчле иҗатчылар җыела. Шуңа да мин һәр уңышымны сөенеп кабул итәм. Сәхнәгә чыгу – үзе бер стимул. ГИТИСка укырга бармадым, дөресен генә әйткәндә, куркып калдым. Җырчылар бик күп, үз тамашачыңны тапмасаң, сиңа урын юк. Икътисадчы булсам да, иҗаттан бер генә минутка да читләшкәнем юк, – ди Гөлназ Гатина.

Сәхнәгә түбәтәй белән чыккан бердәнбер конферансье Инсаф Зариповның да башкалар кебек җырлыйсы, биисе килә икән.

– Җырларга, биергә бик телим дә, әлегә булмый шул, ләкин шигырьләрне оста сөйлим. Кайбер чыгышларны үзем уйлап чыгарам. «Йолдызлык»та мин инде икенче ел, – ди Балтач егете.

«Йолдызлык» гала-концертында сабыйлар чыгышыннан торган 52 номер тәкъдим ителде. Бу юлы сәхнәгә менмәгәннәр бер атнадан «Пирамида» концертлар залында үз сәләтен күрсәтәчәк.

Алисә САБИРОВА.

Авыл халкының күзе яхшырак күрә

Күз авырулары арасында иң еш очрый торганы – катаракта. Аннан кала макулодистрофия һәм глаукома авырулары.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Әмма бу авырулар бик төрле. Глаукома еш очрамаса да, аны дәвалап булмый. Инвалидлык алу сәбәпләре арасында әлеге авыру икенче урында тора. Кызганыч, күп очракта ул бернинди дә билгеләрсез генә узарга мөмкин. Табибка мөрәҗәгать иткәч кенә авыруның бер күзе бөтенләй күрмәве ачыклана, – диде Казан дәүләт медицина университетының офтальмология кафедрасы мөдире Александр Самойлов журналистлар белән очрашу вакытында.

Республика клиник офтальмология хастаханәсенең баш табибы Айдар Әмиров әйтүенчә, бирелә ел саен 30 мең операция ясала.

– Әлеге операцияләрнең күбесе түләүле. Бушлай операцияләрне күбрәк тә ясар идек, әлбәттә, әмма бу финанслау белән бәйле. Бездә зур чират дип тә кистереп әйтеп булмый. Кайбер төр операцияләр өчен, мәсәлән, катарактага бар. Чөнки ул планлы хирургиягә карый. Аңа операцияне бер, хәтта берничә елдан соң да ясарга мөмкин. Нәтиҗәсе барыбер яхшы булачак. Ә глаукома, челтәр катлавына зыян килгән кешеләргә тиз арада ярдәм күрсәтелә. Мондый операцияләр белән проблемалар юк, – ди ул.

Соңгы елларда күз авырулары «яшәрә». Табиблар әйтүенчә, барлык мөрәҗәгать итүчеләрнең якынча 30 проценты – яшьләр, дөрес, алар күп очракта күзлекләрен салыр, ягъни матурлык өчен операциягә килә. Тормышыбызга компьютер, һәр төрле гаджетлар күбрәк үтеп кергән саен, «коры күз» билгеләре дә шулкадәр ешрак очрый. Бу – күзнең кызаруы һәм кибүе дигәнне аңлатты. Әлеге авыру якынча ун еллар элек кенә барлыкка килде, ди табиблар.

– Экологиянең тәэсире бик зур. Моңа кадәр әлеге диагноз зурларга куелса, тиздән балаларда да ачыклана башлаячак. Уйлап карагыз әле, шәһәрдә яшәүче кайсыгызның соңгы тапкыр офык сызыгын күргәне бар? Ни өчен диңгезчеләр һәм биек йортларда яшәүчеләр яхшы күрә? Чөнки аларның ераккка карау мөмкинлеге бар. Без бит гел якында торган әсбапларга гына карыйбыз. Гаджетлардан еш файдаланабыз, компьютер каршында күп утырабыз, хәтта урамга чыккач та, күзебез биналарга төшә. Офиска кергәч, караш дивар белән чикләнә. Нәтиҗәдә күзләребез якынга гына карарга ияләшә. Ә авыл җирләрендә яшәүчеләр кырларны, офыкны күзәтә ала, яшеллек эчендә яши, шуңа күрә дә алар яхшырак күрә, – ди Айдар Әмиров.

Хәер, журналистлар белән очрашуның җитди сәбәпләре дә бар иде. Казан офтальмология мәктәбе тарихы бу көннәрдә зур вакыйгаларны билгеләп үтә. Казан офтальмология хастаханәсе – 95, Казан дәүләт медицина университетының офтальмология кафедрасы – 150, Казан офтальмология җәмгыяте – 110, Казан дәүләт медицина академиясенең офтальмология кафедрасы 95 еллыгын каршылый. Шушы уңайдан Казанга Россия төбәкләреннән 1500 белгеч конференциягә җыелды.

– Мондый саллы даталар белән бик азлар гына мактана ала. Россиядә безнеке кебек клиникалар нибары дүртәү генә. Ел саен Казан медицина академиясе һәм медицина университеты 20 белгеч әзерләп чыгара, – ди Айдар Әмиров.

Казанда кадрлар кытлыгы булмаса да, Татарстан районнарында офтальмологлар җитми. Андый районнарда яшәүчеләр өчен дә Казан табиблары ярдәмгә килә. Алар айга бер мәртәбә барып, халыкка медицина ярдәме күрсәтә.

БЕЛЕП ТОР!

Әгәр күзнең күрүе начарланмаса, башка төрле проблемалар борчымаса, профилактика максатыннан, табибка елына бер мәртәбә күренергә кирәк.

«Коры күз» билгеләре барлыкка килмәсен өчен, компьютер һәм телефон экраннары каршында 1,5 сәгать эшләгәннән соң, күзләрне 7-10 минут ял иттереп алырга кирәк. Бу вакытта мөмкин кадәр ераккка карарга, күзне уңга-сулга, өскә-аска йөртергә киңәш ителә.

Күзләр өчен иң «куркыныч» вакыт – 20 яшькә кадәр һәм 40тан соң. Кагыйдә буларак, нәкъ менә шушы вакытта күз авырулары барлыкка килә дә инде. Шуңа күрә табиблар, балалар кече яшьләрдән ук бадминтон белән шөгыльләнсә яхшы, ди. Әлеге спорт төре күз мускуллары өчен файдалы.

Әтиләребезнең хакы кайда?

ПОЧТАДАН

Бөек Җиңү көненнән соң авылыбызга солдатлар кайта башлый. Әтидән озак кына хәбәр килмәгәч, әни: «Кара пичәтле хат килмәсен тагын», – дип куркып йөргән. Игеннәр өлгерә башлагач, тугыз яшьлек олы апам, башактан орлык уып ашарга дип, басуга менә. Юлдан килгән солдатны милиция дип куркып, күлмәк итәгенә уган бөртекләрен җиргә ташлап кача. Солдат аны янына чакырып, сораша башлый. Сугышка киткәндә дүрт яшьтә калган үз кызын башта танымый эти. Ә инде белеп алгач, апамны кочып алып, елый-елый өйгә кайталар.

Күршеләр: «Бәхетең бар икән әле, синеке кайтты менә», – дип куанышалар. Әмма әтинең авыру икәнен белмиләр әле алар. Фин сугышында катнашу, Суслонгер лагеренда ачка тилмерүләр, салкын окопларда үпкәсенә салкын тидерүләр әтинең сәламәтлеген бик нык какшата.

Әни әтине Хәтнә хастаханәсенә үзе ат җигеп алып китә. Чыкмаган җанда өмет бар, дәваларлар, дип ышана. Аннан Казанга ук илтәләр. Ләкин табибларның игътибарсызлыгы аркасында, бәлки, гомере дә беткәндер инде, әтием якты дөнья белән хушлаша. Әтине авыл Сабан туе көнне атка салып алып кайта әни. Йөрәге нечкәләр түзде икән?! Биш ятим бала, авыру каенана кечкенә генә иске өйдә яшәүче колхозчы тол хатын җилкәсендә кала. «Таяк»ка эшләп йөргән еллар, налог, заем түлисе...

«Ичмасам, сугыштан кайтмаган булса...» – дип, әниемнең өзгәләнгәннәре, ачка тилмерүләребез мәңге оныттырлык түгел. Сугышта Ватан азатлыгы өчен йөреп кайтса да, өйдә үлгәч, без ятимнәргә дәүләттән бер ярдәм дә булмады. Кайда икән безнең әтиләрнең хакы? Кача-поса басуда кул белән чүп утап, күтәреп ташып, сыер асрап, чактан гына ачтан үлми калдык. Энем исә, әбинең чебеннәргә дип куйган гөмбәсен коймак дип ашап, өч яшендә үлеп китте.

Яу кырына озаткан өч улы Берлинга кадәр барып җитеп, җиңү яулап кайтсалар да, әбиебез дә бер тиен пенсия дә күрмичә гүр иясе булды. Ләкин исәннәргә яшәргә кирәк. Без дә көн-төн чыпта сугып, өй салып чыктык. Абый-апалар 14-15 яшеннән урман кисеп, такта ярып җәфаландылар. Лаеш урманнарында газап чигеп, яшьтән авыр эшләрдә эшләп, озак яши алмадылар. Абый да 37 яшендә гүр иясе булды. Әбәт укыса да, алга таба белемен күтәрергә мөмкинлек булмады. «Укыса, әллә кем булыр иде», – ди иде укытучылары. Укырга ярата иде шул. Әниләр чыпта сукканда, лампа яктысында «Газинур», «Намус» романнарын кычкырып укыганы истә. Үзе дә шигырьләр яза иде, алар әле дә саклана.

Ятимнәргә булышу түгел, печән алып кайтканда арбаларын ватып китә иде бригадир. Үзебез күтәреп ташып, сыер асрап, сөт, май, ит, йон, йомырка заданиеләрен түләдек дәүләткә. Мин әтине хәтерләмим дә – өч яшемдә калганмын. Кимсенеп яшәгән, эти дип авыз тутырып әйтәсе килгән чакларым бүген дә истә. Әнинең энесе күршедә генә яши иде. Аның кызыннан: «Мин дә синең әтиеңә «эти» дип әйтим әле», – дип сораганым да хәтердә. Өй салып газапланганда, әнинең йөрәге авырта башлады, өянәкләре вакытында зәңгәрләнеп, тәмам үлеп бетә иде. Беребез үкчәсенә җылы су куябыз, булганда, шикәрле су эчерәбез. Безнең бәхеткә исән калды әни, ләкин шулай да бик озын гомер итә алмады. Толлык газабы үз эшен эшләде.

Исәннәрне кайгырта хөкүмәт. Сугыш ветераннары бүгенге көндә 30-50шәр мең сум пенсия алып, балаларына ярдәм итеп яшиләр, бала саен фатирын, машинасын алып бирделәр. Үзләре үлгәч, балалары сугышып-талашып бүлделәр ул фатирларны. Без дә шул каһәр суккан сугыш аркасында ятим калган балалар. Кая киткән икән безнең әтиләрнең хаклары? Әтинең төсе булып, сугыштан алып кайткан казаны-котелогы гына калды безгә. «Сугышчыларга хезмәт хакы язылып барылган, юлап алып булачак», – дип өметләндерделәр бер елны. Бөтен документларын җыеп, Мәскәүгә җибәреп караган идем, була торган эш түгеллеген аңладым. Нигә 70 ел буена хөкүмәт үзе түләмәгән соң әтиләрнең эш хакларын?

Зөлфия әби,
сугыш чоры баласы.
Казан шәһәре.

Милләтне талантлар баета

Мәдинә Маликова – татар телендә романнар иҗат иткән беренче хатын-кыз язучы, Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты. Ярты гасырлык иҗат дәверендә, аның татар һәм рус телләрендә 30 китабы басылып чыкты, пьесалары республика театрларында сәхнәләштерелде. Быел ул «Арыш тәме» китабы өчен Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Мәдинә ханым, сезнең китапларны укыганда, тормыштагы вакыйгалар күз алдыннан уза. «Арыш тәме»ндә дә үзең белгән кешеләрнең язмышы сурәтләнә сыман. Укучыларыгыз арасында үзләрен танып алганнары юкмы?

– Мондый сүзләр теләсә кайсы язучының йөрәгенә сары май булып ята инде ул. Димәк, син, автор буларак, типик образ тудыра алгансың, дигән сүз бу. Дөньяда булмаганны уйлап чыгару мөмкин түгел, син аның өлгесен таныш кешеләрдән аласың. Монда төп таләп шул: әсәрдә аның кайгы-хәсрәтләре дә, куаныч-шатлыклары да күпләрнең башыннан узган кичерешләргә охшаш, тәңгәл булырга тиеш. Хисләрнең уртаклыгы мөһим. Бервакыт авылга кайткач, кичен капка төбендә утырганда, яныма күрше апа килеп утырды да, хәл-әхвәлне белешкәч: «Мәдинә, сиңа бер дә эч серемне сөйләгәнем юк иде, каян белеп яздың?» – дип сорады. «Күрше бәхете» исемле хикәядә үзен күргән бу. Аптырап киттем. Чөнки һич тә бу апаны күз алдында тотып түгел, бөтенләй башка берәүнең тормышыннан алып язылган әсәр иде ул... «Арыш тәме» романын язарга мине авыл хуҗалыгы институтында эшләүче бер галимә рухландырды. Ул арышның яңа сортларын чыгару белән шөгыльләнә һәм алар илнең уналты өлкәсендә игелә икән. Арыш турында гына түгел, күңеленә якын кешеләр турында да сөйләшеп утырдык аның белән. Галимәнең сөйләгәннәренә авыр язмышлы күрше карчыгының башыннан кичкәннәрне дә өстәдем. Романны илһамланып, яратып яздым. Табигый ки, адәм баласы чын тормыштан әдәби әсәргә шома гына, үзгәрешсез-нисез кереп утыра алмый. Әсәрне беренче тапкыр укыганда, прототипларның ризасыз калуы гаҗәп түгел. Әмма вакытлар узгач, китапны кат-кат укыганнан соң, ризасызлыкларын оныталар, минем хакта бит бу әсәр, дип, мактанып йөри башлыйлар.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТ

– Әсәрдә бернича төрле әһәмиятле проблема күтәрелгән. Шуларның берсе – хатын-кызларыбызның чит ил кешесенә кияүгә чыгып китеп барулары. Моны кайберәүләр үзенчә горурлыкка да саный...

– СССР таркалып, чикләр ачылгач, чит илләргә китүчеләр күбәйде. Кемнәрдер эшкә китә, кемнәрдер – кияүгә. Сагынуларга ничек түзәләрдер, мин чыдый алмас идем. Тик шуны беләм: бер киткәч, кире кайтканнар сирәк. Киресенчә, кунакка кайткан арада: «Ничек яшисез сез монда?» – дип сораучылар бар. Аларның кыяфәте затлы, үз-үзен тотышы дәрәҗәле булып киткәндәй күренә. Андый балаң белән ничек горурланмыйсың! Алдынгы илләр белән чагыштырганда, бездәге яшәеш аларга авыр, күңелсез тоела. Уңган, зирәк ватандашларыбызның дөнья буйлап таралуына риза түгел мин. Үзебездә мантысыннар, тырышлыклары белән үз Ватаныбызны баетсыннар иде. «Арыш тәме»ндәге Ләйсәнне мин акламыйм, әмма аңлыйм. Һәркемнең бәхетле булырга хакы бар!

– Милләттәшләребез арасында, элекке елларда, талантлары югалып калу очраклары ишетеп беләбез. Сезнең «Арыш тәме»ндәге Нәзилә дә шундый язмыш иясе. Сез моны талантларны вакытында күрә белмәү дип уйламыйсызмы?

– Талантларны вакытында күреп алу, аларга белем алырга мөмкинлек тудыру – искиткеч мөһим мәсьәлә. Милләтне талантлар баета, халыкара мәйданда таныта. Милләт үзе дә талантлы ул-кызларының кадерен белсен, аларны бәяләсен, яратсын иде! Бездә исә, минем күзәтүемчә, күпләрнең таланты, сәләте ачылмый кала, югала. Бу – аерым шәхесләрнең фаҗигасе генә түгел, милләтнең байлыгын югалту да. Мин моны Нәзилә мисалында калку итеп күрсәтергә тырыштым.

– Китаптагы «Язгы такыялар» повесте да, «Хатирәләр» бүлеге дә мавыктыргыч. Укучыга танылган шәхесләрне искә төшерәсез...

– «Язгы такыялар» повесте совет чорында язылган иде, цензура чикләүләре аны мин язганча бастырырга мөмкинлек бирмәде. «Хатирәләр» бүлегендә халкыбызның мәгълүм, сөекле шәхесләре, үз күңелемә бик якын кешеләр турындагы язмаларымны урнаштырдым. Укучыларымнан алар турында хуплау сүзләрен шактый ишетәм.

– Әле шушы көннәрдә генә Сезнең «Красный цветок» исемле китабыгызның Милли китапханә уздыра торган ел бәйгесендә (2015) беренче урынны алганлыгы мәгълүм булды. «Кызыл гөл» романын русчага үзегез тәрҗемә иткәнсез. Бу эшкә ничек алындыгыз?

– Бүген татар язучыларының әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итеп бастырып чыгару – авыр мәсьәлә. «Кызыл гөл» романын мин бик яратып язган идем, анда гомумкешелек мәсьәләләрен күтәрергә тырыштым. Аны рус телле укучыларга җиткерү теләге дә көчле иде. 80 яшьлек юбилеема мин үземә шундый бүләк ясарга ниятләдем – романны тәрҗемә итәргә тәвәккәлләдем. Уңышлы булуына ышанычым зурдан түгел иде. Ләкин менә, ни сөенеч, укучылар яхшы кабул иткән бит! «Тәвәккәл таш яра» дигәннәре хак икән.

«Кичер, улым!»

Күптән түгел безнең ишегалдында яшь бер егетне җирләделәр. Стажлы наркоман булган, диделәр. Дозаны арттырганны йөрәге күтәрә алмаган.

Йолдыз ШӘРАПОВА

Олы кайгы кичергән кешеләрне күргәч, күзләремне аска төшерәм мин: елмаеп дәшсәң дә яхшы түгел, эндәшми калсаң да уңайсыз. Теге көнне улын – бердәнбер өметен җирләгән ана белән очрашудан да качып йөрдем. Тик аның үзенең минем белән күрешеп сөйләшәсе килгән икән, өенә чакырды. Газетада эшләгәнемне белгәндер инде, кулыма бернича бит кәгазь тоттырды.

– Бу хатны мин улыма яздым. Ләкин ул хатлар барып җитә торган җирдә түгел инде хәзер. Исәннәр укысыннар да гыйбрәт алсыннар, – диде ятим ана, яшьле күзләрен сөртеп.

Һәрбер юлда – җан авазы, үкенеч, сагыш...

«Кичер, улым! Син бу кара язмышны үзең сайладың. Әниеңнең тынычлыгын, нәни кызчыгыңның елмаюын, хатыныңның бәхетен син шприцка тутырылган үлем суына алмаштың.

Кичер, улым! Гаеп миндә дә булгандыр шул. Хәзер озын, ялгыз төннәрдә уйланып ятам-ятам да, үткәннәр кинодагы шикелле бер-бер артлы күз алдымнан уза. Әтиең безне ташлап икенче гаиләгә киткәч, син ятимлекне сизмәсен, дип, кая куйсалар, шунда эшләдем. Кешедән начар киенмәсен, начар ашамасын дип тырыштым. Әтиеңне бик яратса идең шул. Ул ишекне ябып чыгып киткәндә, күңелеңнең бер нечкә кылы да өзелгәндер, күрәсең. Шул көннән соң син мине тыңламый башладың. Хөрмәтләүдән туктагансыңдыр инде. Күңеленә ачкыч яратырга тырышып, музейларга да алып бардым үзеңне, сәяхәтләргә дә йөрттем. Ләкин җаныңда матурлыкка урын бик аз калган булган инде ул чакта. Аны нәфрәт тутырган булган. Әйләнә-тирәгә, бар дөньяга нәфрәт...

Кайчан бу «эшкә» тотындың син, улым?! Кайсы бәгырьсезе сине бу тозакка әләктерде? Мин бу сорауларга беркайчан да җавап таба алмам инде. Ул җаваплар синең белән бергә мәңгелеккә туфрак астына күмелделәр.

Син тугызынчы сыйныфта укыганда, миңа, эштән фатир бирәбез, диделәр. Аны алыр өчен көнне төнгә ялгап эшләдем. Ниһаять, ул озак көтелгән бәхетле көн килеп җитте. Бергәләп бәйрәм иттек, бәлеш пешереп, дусларыңны да сыйладым. Ә син, оялмыйча: «Әни, эх, шәраб тә булса...» — дип сорадың. Йөрәгем белән каршы булсам да, иптәшләрең алдында дәрәҗәңне төшерәсем килмәде. Өстәлгә алтын башлы шешә менеп кунаклагач, бәйрәм тагын да ямьләнде. Чәркә тоткан кулларыңа, аннан күзләреңә карадым. Юк, оялу да, уңайсызлану да юк иде күзләреңдә. Әллә ничек куркыныч булып китте. Фатир алу шатлыгы да төссезләнеп калды. Авыз ачып сүз әйтмәдем, чөнки син бу чакта мине түгел, дусларыңның сүзен күбрәк тыңлый башлаган идең шул инде.

«Улың бурычка алды», – дип әйтүчеләр ешайган саен, синең төпсез упкын алдында торуыңны ныграк тойдым. Ләкин соң, бик соң иде. Дәваларга, атаклы табибларга да алып бардым. Күпме акча тотканымны үзем дә һәм бер Ходай гына белә. Ләкин дәваланыр-терелер өчен дә ихтыяр көче кирәк шул. Ә синдә ул булмады. Шуңа күрә диспансердан чыгуга, яңадан дусларың янына ашыктың.

Гаеп үземдә дә булды шул, улым. Кичер мине, газиз әниеңне. Дусларыңнан аерып алыр өчен тотарга да армиягә җибәрергә кирәк булган үзеңне. Тормышның ямен, яшәүнең тәмен аңлап кайтыр идең, бәлки. Гомерең бетмәсә, пуля тимәс иде әле үзеңә. Кызгандым шул, күз яшьләремне түктем. Сине армиядән алып калдым.

Өйләнәм, дигәч, сөенечемнең чиге булмады. Киленне дә бер күрүдә кызымдай яраттым. Оныгыбыз тугач, миннән дә бәхетлерәк кеше булдымы икән? Син үзең дә бик сөендең. Күптән инде йөзеңдә елмаю күргәнебез юк иде. Тик бу куаныч озакка бармады. «Кыз тәпие юабыз», – дип, бер-бер артлы дусларың агылды. Аларны озатырга дип чыга идең дә төннәр буе кайтмый идең. Иртән хатыныңның күзләре дә күп елаудан шешенгән була иде. Баласына кушылып, үзе дә елагандыр инде, мескенем. Ләкин син аларны күрмәдең дә, ишетмәдең дә. Аңыңны аракы, наркотик сөреме каплаган иде. Хатының түзде-түзде дә, нәни кызчыгын кочып, әниләренә кайтып китте. Шул көннән соң син дә өйгә юлны бөтенләй оныттың. «Ни белән бетәр икән бу?» – дип, һәр туар көнне куркып, шомланып көтә идем. Менә ул соңгы сәгать сукты. Үзебезнең йортның подвалыннан үле гәүдәңне табып алганнар. Кан тамырыңа шприц кадалган булган.

Син бу язмышыңны үзең сайладың. Ә без, синең кадерле кешеләрең, кайчак күрмәмешкә салышып, кайчак битарафлык күрсәтеп, ялгыш адымыңнан саклап кала алмадык. Синең үлемеңдә без барыбыз да гаепле... Кичер, улым, бәхетсез әнкәеңне!..»

ФГБОУ ВО «КАЗАНСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ АГРАРНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ» ОБЪЯВЛЯЕТ КОНКУРС НА ЗАМЕЩЕНИЕ ВАКАНТНЫХ ДОЛЖНОСТЕЙ ПРОФЕССОРСКО-ПРЕПОДАВАТЕЛЬСКОГО СОСТАВА

1. Доцентов кафедр:

– экономика и информационные технологии - 2
– управление сельскохозяйственным производством - 1

Ученый совет Института Экономики состоится 15 мая 2017 года.

Срок подачи заявлений – один месяц со дня опубликования в газете.

АДРЕС: 420015, г. Казань, ул. К. Маркса, 65.

Фоторепортаж www.shahrikazan.com сайтында

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

ТМТВ премиясе: йолдызлар яңгыры

Узган шимбәдә «Пирамида» концертлар залында TMTV премияләрен тапшыру тантанасы узды. Чара 15:00 сәгатьтә артистларның кызыл келәмнән узуы белән башланып киткән иде. Оештыручылар вәгъдә иткән шаккатырулар да шушында ук башланды – узган ел игътибар үзәгендә Фирдүс Тямаевның «алтылы» машинасы булса, быел Ләйсән Мәхмүтованың мотоциклда килеп туктавы иде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Артистлар атна дәвамында социаль челтәрләрдәге үз аккаунтларында тамашачыларны кызыл келәмгә чакырып мөрәҗәгать итсәләр дә, көн салкын булганлыктан, алар белән очрашып, фотога төшәргә теләүчеләр бик күп булмады.

Чара алдыннан журналистлар белән очрашу вакытында тамашаның биш сәгать дәвам итәчәге турында әйткәннәр иде. Әмма концерт алты сәгатькә сузылып, төнге 11 тулып киткәч кенә тәмамланды.

Быелгы ТМТВ премиясен тапшыру тантанасын Булат Бәйрәмов һәм Айрат Ильясов, Иркә һәм Рифат Зарипов, Айваз Садыйров һәм Назлыгөл Сөнгатуллина – барлыгы алты кеше алып барды. Ә менә алдагы елда шушы ук чараның һәм «Барс-медиа»ның икенче «баласы» – «Татар җыры»ның алыштыргысыз алып баручысы Гөлназ Сәфәрова тамашада күренмәде.

ҖЫРЧЫЛАР ҺӘМ НОМИНАЦИЯЛӘР

Йөздән артык җырчы исә 45 номинациядә бүләкләнде. Алдагы еллардан аермалы буларак, быел «Ел артисты», «Иң яхшы җыр», «Иң яхшы клип» кебек классик номинацияләр белән беррәттән «Эпатаж җырчы» (җиңүчесе – Диана Тажетдинова «Сине көтәм» җыры белән), «Иң яхшы рингтон» (җиңүчесе – Мөнир Рахмаевның «Эх, күр әле» җыры), «Ютуб йолдызлары» (Гүзәл Уразова белән Илдар Хәкимов «Кара күзләремә» җырлары белән), «Иң яхшы ремейк» (Мәликәнең «Алматаның алмасы» җыры) кебек заманча номинацияләр дә булды. «Яхшы блоггер» һәм «Itunes һәм Google Play платформаларында сатылучы җыр» номинацияләрендә җиңүче җырчылар да игълан ителергә тиеш иде. Әмма, ни сәбәпледер, болар телгә алынмады.

Шәхсән үзем чыннан да лаеклы алынган урыннар дигәндә, «Иң яхшы концерт программасы» номинациясендә җиңгән Ильвинаның «Түзә йөрәк» программасын һәм «Гастрольләр рекордсмены» булып танылган Элвин Грейны әйтер идем. Соңгысы елына 748 концерт куйган.

Әмма артистлар һәм номинацияләрдә буталчыклыклар килеп чыкмасын өчен, җырчы тегеяки бу номинациядә җиңүче булып игълан ителү белән үк җырын башкарып кереп китсә, уңышлырак булмас идеме икән, дигән теләк җиткерәсе килеп калды оештыручыларга. Шунысы кызыклы, сәхнә артында сөйләшеп торган вакытта, кайбер җырчылар хәтта үзләренең нинди номинациядә җиңеп чыкканын да белми иде.

Ә Сылуга, мәсәлән, «Эпатаж җырчы» номинациясендә җиңеп чыгуга «дәгъва белдерүе» турында тамаша алдыннан гына билгеле булган. Җырчылар һәм номинацияләр темасын дәвам итсәк, Башкортстанның атказанган артисты Әнвәр Нургалиев үзенең беренче статуэткасын алды. Ул «Романтик җырчы» номинациясендә җиңде. Ә менә «Татар радиосы» ди-джее Булат Бәйрәмов ике – «Гаилә кыйммәтләре» һәм «Иң яхшы алып баручы» номинацияләрендә җиңү яулады.

Болардан тыш, ТМТВнең махсус номинациясе – «Татар сәнгатенә зур өлеш керткән өчен» – эстраданың олпат җырчысы Флюра Сөләйманова да бүләкләнде. Әмма сәламәтлеге начар булу сәбәпле, тантанага гына килә алмады.

Иң күп алкышларны Башкортстаннан чыккан җырчылар җыйды. Тамашачы Айдар Галимов, Әнвәр Нургалиев, Радик Юлъякшин, Хәния Фәрхи, Филүс Каһиров һәм Салават Фәтхетдиновның чыгышларын аеруча яратып кабул итте. Шулай ук Гүзәл Уразова, Зәйнәб Фәрхетдинова һәм «Артур-Марат» дуэты да йокымсырап утырган тамашачыны җанландырып җибәрде. Ә менә берничә номинациягә дәгъва кылсалар да, концертта Фирдүс Тямаев, Илсөя Бәдретдинова чыгыш ясамады. Шулай ук тамашачылар әлеге матур бәйрәмдә Ришат Төхвәтуллинны да күрергә теләүләрен җиткерде. Ә менә Салават Миңнеханов белән Гүзәлем бик матур образларда кызыл келәмнән узсалар да, ни өчендер, сәхнәдә алар өчен урын табылмаган...

Тантананың номерларына килгәндә, былтыргы сигвейлар быел мотоциклларга, голландия бакчалары туган якның алма бакчаларына алмашынды. Эксклюзив графика, танцеваль һәм театральләштерелгән номерлар, спецэффектлар – ТМТВ премиясенә килгән тамашачыларга әнә шундый шоу тәкъдим ителде. Үзенчәлеге, зәвыгы белән иң истә калган номерлар дигән вакытта Ильвинаның һәм Лилия Хәйруллинаның чыгышларын әйтергә мөмкин.

Соңгы вакытларда төрле матбугат чараларында: «Миңа хәзер «Татар җыры» кебек тамашалар кызык түгел...», «...Иң соңгы чыгыш ясаган җырчы иң яхшысы дигән сүз түгел әле, менә минем хәзер ахырга кадәр көтеп торасым килми, шуңа күрә алданрак чыгыш ясап, кайтып китәргә тырышам», – дип белдергән Салават Фәтхетдинов иң ахыргы чыгыш ясады. Ул «Ике гасырның иң яхшы җырчысы» номинациясендә җиңеп чыкты. Һәм, алда язганымча, тамашачыларның алкышларына күмелде. Концертка килүчеләрне, бәлки, Салават һәм Радик Юлъякшин арасындагы тарткалашу да кызыксындыргандыр. Журналистлар белән очрашу вакытында Элвин Грей:

– Мин батл турында игълан иткәннән соң, Салават абый белән очрашканыбыз юк. Беренче тапкыр ТМТВ премияләрен тапшыру тантанасында күрешәбез, – дигән иде бит.

Әмма, шөкер, әлеге буыннар каршылыгы турында сәхнәдә бер генә авыз сүз дә кузгатылмады. Мондый тема өчен урыны да, көне дә ул түгел шул.

«ҖЫР БУЛМАСА, ҖЫРЧЫЛАР АЧТАН ҮЛӘ»

Көтеп алынган, һәр кешенең диярлек телендә һәм игътибарында була торган тамаша турында, һәр елдагыча, төрле фикерләр ишетергә туры килде. Алар турында озаклап тукталасы килми, шулай да халык шагыйре Роберт Миңнуллинның һәм язучы, юмор остасы Алмаз Хәмзинның гомумән татар җырына, мондый төр тантаналарга карата фикерләрен җиткерсәк, оештыручыларга – файдалы, ә тамашачыларга кызыклы булыр иде дип уйлыйм.

Премия җиңүчеләрен халыкка җиткерергә дип сәхнәгә менгәч, Роберт Миңнуллин: «Гәрчә җырчылар үзләре әйтмәсәләр дә, монда яңгыраган берничә җырның авторы да әле мин», – диде, җырларның авторларын игълан итмәүгә басым ясап. Аннан соң, чыгышын дәвам итеп:

– Халкыбыз җыр турында нәрсә уйлый икән, дип, Нәкый Исәнбәтнең өч томлык мәкальләр һәм әйтемнәр җыентыгын карап чыктым. Шуннан берничә мәкаль таптым: «Җырның җыртыгы юк». Кызганыч, бар, аларны хәтта ямарга кирәк. «Икмәк булса, җыр да була», – диелсә дә, җырчылар киресенчә уйлый. Артист өчен җыр – икмәк. «Җыр тамак туйдырмый», әлбәттә, әмма җырчыларны туйдыра. «Җырсыз яшәп булмый». Чынлап та, яшәп булмый! Җыр булмаса, җырчылар ачтан үләчәк. Яшәсен җыр, яшәсен татар җыры! – диде ул.

Алмаз Хәмзинга: «Шушы 45 номинация арасында тагын нинди күрергә теләр идегез?» – дип сорау бирдек. Ул:

– «Тәрбия җырлары» дигән номинация җитми. Җыр бит халыкны тәрбияләргә тиеш. Аның көе дә, тексты да уйландырырга мәҗбүр итә торган тирән эчтәлекле булсын иде. Сабый бишектә чагында туган телендә сүз әйтә алмаса да, көй ишетеп, кулларын-аякларын хәрәкәтләндерә. Шул вакытта ук күңеленә тәрбия орлыклары салына. Тамаша бик шәп, «Барс-медиа» да тырыша. Әмма күңелне бер нәрсә борчый: премияләрне халык сайласын иде, ә монда аларны бармак бөгеп санап, өләшү генә килеп чыга. Шоу бар, акча бар, техник мөмкинлекләр күп, әмма көй-эчтәлек юк. Хәзер, гомумән, тамашачы зомбилаштырылган. Аңарда өмет тәрбияләргә кирәк иде, – дип җавап бирде.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1642. Гомуми тираж – 6179.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 702. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы